**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның «01» декабреннән № 336

**«Гамәлгә куючы вәкаләтләрен беркетү турында»**

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2010 елның 19 ноябрендәге 3-14 номерлы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Муниципаль йөкләмәне формалаштыру һәм раслау һәм аны финанс белән тәэмин итү өлешендә муниципаль йөкләмәне раслау буенча гамәлгә куючының вәкаләтләрен Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына беркетергә.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына югарыда күрсәтелгән чараларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә башкарырга.

3. Муниципаль йөкләмәне формалаштыру һәм раслау һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесе тарафыннан финанс ягыннан тәэмин итү өлешендә муниципаль йөкләмәне финанслауны раслау буенча гамәлгә куючы функцияләрен үтәү вәкаләтләрен туктатырга.

4. Әлеге карарны мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**